Милли хәрәкәт юлбашчылары

«Туган тел» җәмгыяте Самар өлкәсендә мәчетләр салуда көрәште

Самар татар милли хәрәкәте чирек гасырлык юлын горурлык белән искә ала. Һәр чор үзенең шәхесләре белән тарихка керә.

Чорны шәхесләр бизи, ә татар милли хәрәкәтен шәхесләр әле рухи яктан баета да.

Егерменче гасырның ахырын Михаил Горбачев чоры, дип бәялибез. Аның хаталары булды, ләкин дә Михаил Сергеевичның хаталарын һәм уңышларын бизмәнгә салсак, һичшиксез, уңыш үлчәве авыррак булачак. Горбачев чоры - динебез Исламның тормыш-көнкүрешкә әйләнеп кайтуы һәм татар милли хәрәкәтенең аякка басуы.

"Туган тел" исеме белән халыкка танылган татар дәрте көчле шәхесләр аша үзен белдерде. Татар җәмгыятенең юридик зат итеп юстиция органнарында теркәлүне Шамил Әхмәров җитәкләде, шулай ук җәмгыятьнең Уставын булдыруда да көч куйды.

Исеменә күрә җисеме

Озак көттерми милли хәрәкәткә яңа ир-егетләр килә башлады. Шулар арасында Фатыйх углы Рәшид Абдуллов үзенә генә хас сыйфатлары белән аерылып тора.

Ул сыйфатларга тукталмый мөмкин түгел, чөнки алар - һәр юлбашчыга, һәр әйдаманга кирәкле сыйфатлар.

Фирмаларда кул астында хезмәт иткән адәм баласын куркытып, акча белән эшләтергә була. Милли хәрәкәттә башка үлчәүләр.

Рәшид Абдулловның мин күргән сыйфатлары.

Алар түбәндәгеләр:
сабырлык,
түземлелек,
тәрбиялелек,
югары интеллект,
киңәшә белү,
кеше фикеренә колак салу,
төрле тәкъдимнәрдән берсен сайлап ала белү,
жаны-тәне белән динебез Исламга тугрылык,
татар телен ярату,
җитәкчеләр белән сүз алып бару осталыгы,
башкаларны ышандыра алу,
уңганлык һәм максатчанлык.

Рәшид исеменең тәрҗемәсе. Туры юлдан баручы. Батыр. Кыю. Зирәк. Җитлеккән. Ничек инде шуннан соң шикләнәсең: "Исем кешене үзе артыннан алып бара," - дигән гыйбарәгә.

Рәшиднең зур һәм калын гына амбар кенәгәсе бар иде.

Беренче иганәчеләребез

"Туган тел" җәмгыятенә килгән һәр кешене шунда теркәп барды. Адресын, телефонын язып куяр иде. Ул вакытта бизнес тирәсендәге адәмнәр татар милли хәрәкәтеннән уттан курыккандай шүрләделәр. Шулай да батыр йөрәклеләре дә табылды. Алар - Равил Яһудин, Вазыйх Мөхәммәтшин, Сания апа Каюмова, Хәбил Бикташев, Әнвәр Бульхин, Җәмил Вәлиуллин. Шунысы куанычлы ки, бу исемлек бик тиз үсә барды һәм татар җанлы милләтпәшләребез бәйрәм чыгымнарын үз өсләренә алдылар.

Татар китабы татарны саклый

Хәрәкәтнең башында китаплар сатуны оештырдык һәм бу четерекле мәшәкатьне үз өстенә Рәшид Абдуллов алды.

Ул елларда мин Казанга еш йөрдем. Казаннан капчык-капчык

1993 ел. «Туган тел» җәмгыяте мөдире Рәшид Абдулов Тольятти шәһәрендә мәчет салу буенча җыелыш уздыра

китап төяп кайта идем, Самарда мине Рәшид каршы алды.

Әлбәттә, китапны без акча эшләү ниятеннән түгел, халыкны идеологик яктан коралландыру ниятеннән ташыдык һәм, әйтергә кирәк, бу юл дөрес юл булып чыкты.

Шунысы шиксез. Татар китабын укымаган адәми зат татар мәнфәгатен яклаганда сай сөрүчән була һәм аның терәне кыска гомерле. Йөрәкнең милләт өчен януы, бәхәссез, кирәк нәрсә, ләкин дә төрле даирәдәге очрашуларда милли лидердан үзенең мәдәниятен, тарихын, телен белү зарури.

Халык белән сөйләшер өчен мәйдан кирәк

Ә мәйдан үзеннән-үзе бәйрәм сорый.

Фатыйх углы Рәшид Абдуллов "Туган тел" җәмгыятен җитәкләгән чорда гөрләтеп Сабан туйлары уза башлады.

Колачлы итеп "Уйнагыз, гармуннар!" сәхнәгә күтәрелде. Беренче «Уйнагыз, гармунар!»ны мин кызым Наилә белән алып бардым. Киров мәйданындагы Мәдәният Сарае гөрләп торды. Архивтагы фотоларны карап утырам да, күңелгә моңсулык килә, чөнки гармунчыларның бик күбесе инде мәңгелеккә күчкәннәр.

Абдуллов чорында Самарның төрле җирләрендә Сабан туйлар гөрләде. Чыршы бәйрәмнәрендә Кыш бабай белән Кар кызы татарча сөйләшә башладылар. Мәдәни ягын мин алсам, Абдулловка бүләкләр булдыру мәшәкатеятты. Соңгысы иң авырлардан саналды, санала һәм саналачак та. Теләсә кайсы заманда акча табу мәшәкате төп проблем булып тора.

Ул елларда нәрсә эшләсәң дә, яңалык иде, чөнки гомер-гомергә татарны кысып килделәр. Максат бер иде - бердәм сәвит халкын әвәләндерү. Монысы максатның тышкы кабыгы. Эче - урыслаштыру булды.

Егерме ел элек Аврорадагы сукырлар өчен Мәдәният Сараенда Рәшид Абдуллов татар егетләре-кызлары өчен дискотекалар оештырып җибәрде.

Татарларның мәгълүмати кырга чыгуы

Шулай да, Рәшид әфәнде көндәлек бәйрәм мәшәкатьләренә чумып югалмады. "Бердәмлек" гәҗитәсен ачу мәшәкатьләрендә янды, "Яктылык" мәктәбен булдыруда көйде. Әлбәттә, бу олуг мәшәкатьләрне ул үзе генә ерып чыга алмаган булыр иде, әгәр дә җәмгыять әгъзалары командаларга бүленеп эшләмәсәләр. Абдулловның осталыгы шунда ки, кемгә нинди йөк бирәсен ялгышмый күзаллый ала иде. Ул миңа да "министр культуры" мөһерен чәпәде.

"Туган тел" өлкә биеклегенә чыга

Самар өлкә татар җәмгыяте "Туган тел" исемен Самар шәһәре кысаларында гына калдырмыйча, өлкә күләменә чыгару кирәк иде. Шул нияттән Похвистнева, Тольятти һәм Сызранда җәмгыятьнең мөстәкыйль бүлекчәләре барлыкка килде. Похвистневода Булат Хәмитов, Тольятти шәһәрендә Роза һәм Ирек Кәримовлар, Сызранда авиация полковнигы Галиулла Габдрәшитов бу йөкне үз өсләренә алдылар.

Тольятти һәм Сызран араларын Рәшид белән миңа озак гизәргә туры килде. Рәшиднең черегән кара "Волга"сы ничек кенә түзгәндер.

Юлда ватылмый калмаган чак юк иде. Көпчәк тишелүләр сансыз булды. Ә бит ары-бире йөрүләрне көзен һәм кышын алып барырга туры килде.

"Туган тел" Татарстанның бәйсезлеген яклады һәм Җәмигъ мәсҗиден салуда көрәште

Тагын бер нәрсәгә игътибар итү кирәктер. Татар милли хәрәкәтенең аякланчы Самар Җәмигъ мәсҗиден салу һәм Татарстанның мөстәкыйльлек яулау вакытларына туры килде. Урыс шовинистлары бер яктан Татарстанны талыйлар, икенче яктан Самар Җәмигъ мәсҗиден салдырыга каршы көрәш алып баралар. Урыслар һәм казаклар "Шипка" кинотеатры янында кат-кат нәфрәт митинглары уздырдылар. Шул авыр чорда барчабызны да туплап, бер фикергә килеп, без бар куәтк Татарстанның бәйсезлеген якладык, Җәмигъ мәсҗиден төзергә җир алуга ирештек.

Мәсҗид салу мәсьәләсенә кагылган кискен сөйләшү Самар өлкә администрация бинасында узды һәм бу очрашуга Абдуллов мине - Шамил Баһаутдинны җибәрде. Ак йорттагыларның бар максаты гыйбадәтханәне Козелкида салдыру иде. Аларның һәр сорауларына төпле каршылык күрсәтеп, "Туган тел" җәмгыятенең позициясен якларга Ходай көч, зирәклек һәм зиһен сафлыгы бирде. Ходай Тәгалә ярдәме белән Самар Җәмигъ мәсҗиде бүгенге урында салынды.

Рәшид Абдулловның суык тынычлыгы, Вагыйз хәзрәт Яруллинның җитәкчеләр алдында булган дәрәҗәсе, Равил ага Яһудинның чиксез темпераменты һәм халык дипломатиясен оста куллануы һәр зур проектны ахырына җиткезергә ярдәм итә иде.

Бу эшнең ахыры хәерле булды, чөнки олуг мәшәкатьне ерып чыгар өчен "Туган тел" җәмгыяте, Вагыйз хәзрәт Яруллин һәм аның фикердәшләре бер команда булып эшләдек.

Самар өлкә түрәсе Виктор Тархов татарларны яратты

Рәшид Абдуллов белән минем өлкә түрәсе Виктор Тарховка "Бердәмлек" гәҗитәсен ачу мәсьәләсе буенча бару да истә калган. Бик эссе көн булуга карамастан, Рәшид белән икебез дә түбәтәйдән. Виктор Александрович безне диккать белән тыңлады һәм сорау бирде. "Татарларга гәҗитә, радио, телевидение, мәктәп кирәк. Ни өчен башкорт, чуаш, мукшылар берни сорамыйлар?" - дип безгә текәлде. Рәшид минем аякка төртеп куйды, бу инде "Сөйлә!" дигәнне аңлата иде. "Виктор Александрович, чуаш, мукшы, башкорт беркайчан да дәүләт тоткан халык түгел. Ә татарлар - Болгар дәүләтен шаулаткан милләт, Казан ханлыгы белән идарә иткәннәр. Без кушылмадык, безне яулап алдылар. Тамырларда һаман да дәүләтчелек каны ага", - дип зәп-зәңгәр кан тамырларымны күрсәттем.

Кабинетта тынлык урнашты. Бераздан Тархов: "Сезне аңладым. Гәҗитәгез булачак, калганнарына да каршылык күрсәтмәбез", - дип өстәп куйды.

Зур түрәләргә Абдуллов курыкмый керде

Зур түрәләргә барганда Рәшид Абдуллов бик нык әзерләнеп бара иде. Төрле версияләрне күздә тотты. Кемгә керсәк тә, өстәлнең ике ягына кара-каршы утыра торган булдык. Аяклар бер-берсенә терәлгән булыр. Рәшид арттырып җибәрсә, аның аягына мин басам, мин арттырсам, минем аякка Рәшид баса.

Өлкә радиосында "Иделкәеминкәем" радиожурналын алып барулар, телевидениедә татарлар турында тапшырулар оештыру - барчасы да Абдуллов чорына туры килде.

Рәшид Абдулловның акыл офыгы шулкадәр киң иде ки, ул теләсә кайсы аудиториядә чыгыш ясады, сәяси дошманнарын кабыргаларына салырга хәленнән килде.

Рәшид Абдулловның нәсел орлыгы

Рәшидтәге дистәләгән сокланргыч сыйфатлар, әлбәттә инде, күктән төшмәгәннәр. Рәшид Абдулловның әтисе — завод директоры булган кеше. Инкыйлабтан соң әти-әнисе — клубларда татар спектакльләре куеп йөргән милләтпәрвәрләр. Татар телебезгә мәхәббәт, татар культурасына хөрмәт, динебез Исламга ихтирам Рәшидкә әнкә сөте белән сеңгән.

"Туган тел" тарихында Фатыйх углы Рәшид Абдуллов - кызыл хәрефләр белән язарлык олуг шәхес.

Шамил БАҺАУТДИН.